# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№ 2** 05.12.2019 ел

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль
районының Шуган авыл җирлеге составына керүче
Иске Смыловка торак пунктына 2020 елда гражданнарның
үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Шуган авыл җирлеге Иске Смыловка торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

3. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Иске Смыловка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 700 (җиде йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә. Көндезге формада укучы студентларга, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфганстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга катнашучыларга 350 (өч илле йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү Иске Смыловкасы;
- Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, Иске Смыловкасы авылы суларын чыгаруны оештыру;

.- Иске Смыловкасы авылы юлларына кышкы һәм җәйге хезмәт күрсәтү.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда, Мөслим муниципаль районы рәсми сайтының http/ muslumovo.tatarstan.ru веб-адресына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм Мөслим муниципаль районы, Иске Смыловка авылы, Совет урамы, 12 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Шуган авыл җирлеге башлыгы** **А.Ю.Басорина**